# 05.02.2021 ел. Татар халык иҗатын өйрәнү.

(Җырлы-биюле уеннар уйнау)

**Максат**: балаларда җыр һәм музыканың характерына туры китереп хәрәкәт итү күнекмәләре формалаштыру; җыр һәм биюләрне мөстәкыйль рәвештә башкарырга омтылыш булдыру; халык авыз иҗаты әсәрләре белән кызыксыну һәм аларга карата мәхәббәт тәрбияләү.

Уеннар балаларга шатлык китерә, аларның теләкләрен, ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш. Уен – балалар эшчәнлегенең төп төре. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әверелдерә, балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен ача, теләк-омтылышларын берләштерә.

**Җырлы-биюле уен "Чума үрдәк, чума каз"5-6** яшьлек балалар өчен. Уйнаучылар кара-каршы ике рэт булып тезеләләр дә, парлашып кулга-кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар :

Чума үрдәк, чума каз, тирән күлне ярата шул ярата
Ләйсән үзенә иптәш эзли, белмим кемне ярата шул ярата
Айратны ул ярата шул ярата.

